# Текст

*1)* **Дөньяда һәр нәрсәнең чиге дә, чамасы да бар. 2) Эчә торган төче су планетадагы бар суларның нибары ике генә процентын тәшкил итә. 3) Калган туксан сигез проценты эчәргә яраклы түгел. 4) Шуның өстенә, ул ике процент һич тә артмый, бәлки, тотылган саен кими генә бара...**

**5) Ярый ла, безнең якларда хәзергә эчәр суның запасы күп. 6) Шул сәбәпле әле хәзергә су кытлыгы көтелми. 7) Әмма кайбер җирләрдә суны хәзер үк инде самолетта ташып, җан башыннан бүләләр. 8)Кайбер зур шәһәрләрдә гап-гади суны стаканлап сатуларын да онытмыйк.**

**9) Бу хәлләр безне дә сагайтырга, табигатьнең бу кадерле бүләгенә игътибарлы булуны искәртергә тиешле. 10) Чишмәләре кибеп, сусыз калган авыллар бездә дә юк түгел.**

**10) Ни сәбәпле корый чишмәләр? 11) Чишмә чыга торган урман яки агачлык киселеп бетә дә чишмәнең чыганагы киемен салдырып алган кеше шикелле ялангачланып кала. 12)Ул урынны терлек-туар таптый, ул чүпләнә, пычрана. 13) Шуннан соң чишмәнең корымый хәле калмый. 14) Чишмә артыннан, акрынлап, аның суы белән туклана торган инеш тә кибә. 15) Ул арада, дым булмагач, чишмә һәм инеш буенда куаклар, үләннәр, болыннар да корый, бу тирәгә кош-корт та оя ясамый башлый. 16) Шулай итеп, кошлар сайрап торган гаҗәеп матур бер табигать почмагы тиз арада җансыз, күңелсез, ташландык бер чокыр-чакырга әверелә.**

**17) Мондый күңелсез хәлне булдырмаска мөмкин бит.**

**18) Яшел яфраклар шаулап, болыннар, чирәмлекләр хуш ис бөркеп, чишмәләр чылтырап аккан ямьле урында яшәү нинди зур бәхет, нинди шатлык! 19)Шуның өстенә, сәламәтлеккә дә нинди файдалы.***(Г. Бәшировтан.)*

# Проблема

Бу текстта Г. Бәширов кешелеккә чынлап торып куркыныч янаган проблемаларның берсе – яшәешнең нигез ташы булган табигатькә карата мөнәсәбәт, аңа сакчыл караш мәсьәләсен күтәрә.





# Автор позициясе

**Язучы: “Мондый күңелсез хәлне булдырмаска мөмкин бит”, - ди.**

# Минем позициям

Минем фикеремчә дә, бу хаталарны соңыннан төзәтү авыр, хаталарны булдырмау җиңелрәк, хәерлерәк.



***Ахыр чиктә табигатьне һәртөрле куркынычтан халыкның мәхәббәте саклап кала алыр иде.***

*Ж. Дорст, француз галиме*

## В 1

2, 18 нче җөмләләрдән **ирен гармониясенә буйсынган** сүзләрне табыгыз.

***2) Эчә торган төче су планетадагы бар суларның нибары ике генә процентын тәшкил итә. 18)Яшел яфраклар шаулап, болыннар, чирәмлекләр хуш ис бөркеп, чишмәләр чылтырап аккан ямьле урында яшәү нинди зур бәхет, нинди шатлык!***

# В 2

**9, 10 нчы җөмләләрдәге тартым белән төрләнгән исемнәрне табыгыз, килешләрен билгеләгез?**

9) ***Бу хәлләр безне дә сагайтырга, табигатьнең бу кадерле бүләгенә игътибарлы булуны искәртергә тиешле. 10) Чишмәләре кибеп, сусыз калган авыллар бездә дә юк түгел.***

# В 3.

- 19 нчы җөмләдән әйтелеше язылышына туры килмәгән сүзләрне языгыз.

***19) Шуның өстенә, сәламәтлеккә дә нинди файдалы.***

# В 4

- **8-10 нчы җөмләләрдән ясагыч кушымча ялгану ысулы белән ясалган сыйфатларны языгыз.**

8) Кайбер зур шәһәрләрдә гап-гади суны стаканлап сатуларын да онытмыйк.

9) Бу хәлләр безне дә сагайтырга, табигатьнең бу кадерле бүләгенә игътибарлы булуны искәртергә тиешле. 10) Чишмәләре кибеп, сусыз калган авыллар бездә дә юк түгел.

# В 5

## 9 нчы җөмләдәге алмашлыкларның төркемчәләрен билгеләгез.

***9) Бу хәлләр безне дә сагайтырга, табигатьнең бу кадерле бүләгенә игътибарлы булуны искәртергә тиешле.***

# В 6

**8-10 нчы җөмләләрдән инфинитив фигыльләрне языгыз.**

8) Кайбер зур шәһәрләрдә гап-гади суны стаканлап сатуларын да онытмыйк.

9) Бу хәлләр безне дә сагайтырга, табигатьнең бу кадерле бүләгенә игътибарлы булуны искәртергә тиешле. 10) Чишмәләре кибеп, сусыз калган авыллар бездә дә юк түгел.

## В 7

**1-2 нче җөмләләрдән рәт гармониясенә буйсынмаган сүзләрне языгыз.**

1) ***Дөньяда һәр нәрсәнең чиге дә, чамасы да бар. 2) Эчә торган төче су планетадагы бар суларның нибары ике генә процентын тәшкил итә.***

- **В8.**
  **13-15 нче җөмләләр арасыннан хәзерге заман сыйфат фигыль булган җөмләнең номерын языгыз.**
- **13) Шуннан соң чишмәнең корымый хәле калмый. 14) Чишмә артыннан, акрынлап, аның суы белән туклана торган инеш тә кибә. 15) Ул арада, дым булмагач, чишмә һәм инеш буенда куаклар, үләннәр, болыннар да корый, бу тирәгә кош-корт та оя ясамый башлый.**

# С2

- Текст буенча сочинение языгыз.
- Автор позициясен билгеләгез. Сез автор белән килешәсезме? Ни өчен?
- Фикерегезнең дөреслеген раслау өчен, укылган текстан 2 мисал китерегез. Бу вакытта файдаланган җөмләләрнең номерларын языгыз яки тексттан цитата китерегез.
- Сочинениенең күләме 70 сүздән дә ким булмаска тиеш.